РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

Постановление | Карар

07.03.2023 г.Чистополь № 25

Гавами тыңлауларны билгеләү турында

Чистай муниципаль районы Советының 2018 елның 18 июлендәге 35/5 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, «Гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» Нигезләмә нигезендә, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хуҗаларының тормыш шартларына, хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кеше хокукларын үтәү максатыннан

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.
2. Билгеләргә:
2.1. Гавами тыңлаулар уздыру датасы – 28.03.2023 ел.
2.2. Үткәрү вакыты (дәвамлылыгы) әлеге карар басылып чыккан көннән алып гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр бер айдан артык түгел.
2.3. Гавами тыңлаулар уздыру урыны:
- ТР, Чистай районы, Луч бистәсе, Җиңү урамы, 16 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында 16 сәгать 00 минутта;
- ТР, Чистай районы, Ак Тау авылы, Үзәк урам, 24 нче йорт адресы буенча урнашкан бинада 17 сәгать 00 минутта.
2.4. Фикер алыша торган мәсьәләгә карата тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне түбәндәге адрес буенча җиткерергә мөмкин: ТР, Чистай районы, Луч бистәсе, Җиңү ур., 16 йорт (эш көннәрендә - 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр).
2.5. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар

бирү вакыты: 2023 елның 28 марты, 15.00 сәгатькә кадәр.

3. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитетын (алга таба - оештыру комитеты) түбәндәге составта төзергә:

Иванов К.В. – Чистай муниципаль районы Башлыгының беренче урынбасары, оештыру комитеты рәисе;

Емельянов П.Б. – Чистай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары, оештыру комитеты рәисе урынбасары;

Маркин В.О. – “Шәһәрне көйләү һәм инфраструктура үсеше” МБУның әйдәп баручы белгече, оештыру комитеты секретаре (килешү буенча);

Шумилов А.А. – Чистай муниципаль районы башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы, оештыру комитеты әгъзасы;

Зарипов Р.Н. - Чистай муниципаль районы башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы, оештыру комитеты әгъзасы;

Мәгъсумов Р.М. - Чистай муниципаль районының Чистай авыл җирлеге башлыгы, оештыру комитеты әгъзасы (килешү буенча).

4. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә әлеге карарны «Чистай хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http://chistopol.tatarstan.ru.урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Башлыгы Д.А. Иванов